| МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

17.04.2019 Казан ш. № 1236-р

**Татарстан Республикасының Менделеевск муниципаль районы территориясендә бүлгеч челтәрнең саклау зонасы чикләрен билгеләү турында**

Россия Федерациясе Җир Кодексының 56, 106 ст., «Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы № 69-ФЗ Федераль законга, «Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында» 13 июль 2015 ел № 218-ФЗ Федераль законның 32 ст., Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләрен раслау турында» 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләренә туры китереп, һәм «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ мөрәҗәгате нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.08.2007 ел, № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турында нигезләмәсенә таянып, Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы карар чыгарды:

1. ЭПУ «Елабугагаз» газ бүлү челтәре объектының Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы территориясендә урнашкан саклык зонасын территорияне файдалануның аерым шартлары булган зона чикләре урнашкан урынның текстлы һәм график тасвирламасындагы мәгълүматка, газ бүлү челтәре чикләренең характерлы нокталарының координаталары исемлегенә туры китереп расларга.

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән газ бүлү челтәрләре объектының саклау зоналары чикләренә тулысынча яки өлешчә туры килгән җир кишәрлекләренә газ бүлү челтәрен эксплуатацияләү срогына Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган газ

бүлү челтәрен саклау кагыйдәләрендә каралган чикләүләр (йөкләүләр) кертергә.

1. «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖга тәкъдим итәргә:

1) газ бүлү челтәренең саклау зоналары турында мәгълүматны Дәүләт күчемсез милек кадастрына кертү чараларын күрергә;

2) әлеге карарның 1 нче пунктында күрсәтелгән газ бүлгеч челтәрнең саклык зонасына кергән әлеге карарның 2 нче пунктында күрсәтелгән җир кишәрлекләренә чикләүләр кертелү турында мәгълүматны Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрына кертү чараларын күрергә;

3) әлеге карар кабул ителүгә 5 көн эчендә аны һәм әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән территорияне кулланунының аерым шартлары булган зона чикләре урнашкан урынның текст һәм график тасвирламасының электрон формасын, газ бүлү челтәрләренең (газүткәргечләрнең) андый зоналары чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеген теркәп, газүткәргечләрнең саклау зоналары җир төзелеше объектлары карталарын (план) XML-схемалар кулланып төзелгән һәм бирелгән мәгълүматның укылышын һәм контролен тәэмин итүче XML форматындагы файллар рәвешендә, әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән газ бүлү челтәрләренең (газүткәргечләрнең) саклау зоналары турында һәм әлеге карарның 2 нче пунктында күрсәтелгән җир кишәрлекләренә булган чикләүләрне (йөкләүләрне) Күчемсез милек бердәм дәүләт реестрына кертү өчен хокукларны регистрацияләү органына юлларга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары А.И.Галиевка йөкләргә.

**Министр в.б.** **А.И.Галиев**